Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советы өченче чакырылышының
унтугызынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советы карары

2018 ел, 26 апрель № 145

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы милкендә булган төзелеш объектларының төп фондын һәм (яисә) тормышка ашырылмаган чыгымнарын исәптән чыгару тәртибе Положениясен раслау турында

Россия Федерациясе Гражданнар кодексы, 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” гы, 2002 елның 14 ноябрендә кабул ителгән 161-ФЗ номерлы “Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятияләр турында” гы, 2011 елның 6 декабрендә кабул ителгән 402-ФЗ номерлы “Бухгалтер хисабы турында” гы Федераль Законнарга, бухгалтер хисабын алып бару тәртибен регламентлаучы Россия Федерациясе финанс Министрлыгы боерыкларына, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына таянып, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль район Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы милкендә булган төзелеш объектларының төп фондын һәм (яисә) тормышка ашырылмаган чыгымнарын исәптән чыгару тәртибе Положениясен расларга.
2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы милкендә булган төзелеш объектларының төп фондын һәм (яисә) тормышка ашырылмаган чыгымнарын исәптән чыгару тәртибе Положениясенең таләпләрен саклау һәм куллану буенча, район муниципаль учреждение һәм предприятияләре җитәкчеләрен тәэмин итәргә.
3. 2008 елның 19 маенда кабул ителгән 23 номерлы “Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы милкендә булган төзелеш объектларының төп фондын һәм (яисә) тормышка ашырылмаган чыгымнарын исәптән чыгару тәртибе” Положениясен раслау турында” дигән Питрәч муниципаль район Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтына (http://pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүгә алуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов.

Питрәч муниципаль район
Советы карарына кушымта № 1
26 апрель, 2018 ел № 145

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы милкендә булган төзелеш объектларының төп фондын һәм (яисә) тормышка ашырылмаган чыгымнарын исәптән чыгару тәртибе
Положениясе

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы милкендә булган төзелеш объектларының төп фондын һәм (яисә) тормышка ашырылмаган чыгымнарын исәптән чыгару тәртибе Положениясе (алга таба – Положение) Россия Федерациясе Гражданнар кодексына, 2002 елның 14 ноябрендә кабул ителгән 161-ФЗ номерлы "Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятияләр турында" гы Россия Федерациясе Законына, ПБУ 6\01 "Исәпкә алуны төп чаралары" бухгалтер хисабы Положениясе, бухгалтер хисабының төп чаралары методик күрсәтмәләренә, 2003 елның 13 октябрендә кабул ителгән 91н номерлы Россия Федерациясе финанс Министрлыгы боерыгына, дәүләт хакимияте органнары өчен бухгалтер хисабы исәпләре, җирле үзидарә ограннары, бюджеттан тыш дәүләт идарәсе фондлары органнары, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре буенча Бердәм планга һәм 2010 елның 1 декабрендә кабул ителгән 157н номерлы Россия Федерациясе финанслар Министрлыгының аны куллану Инструкцияләренә бәйле рәвештә эшләнелде.

2. Положение, төп чараларга караган муниципаль милекнең, шулай ук чыгымнар буенча тормышка ашырылмаган һәм (яисә) мөмкин булмаган төзелеш буенча (мәсәлән, проект-смета эшләре, җир кишәрлеге чыгымнары буенча һ.б.),

3. Исәптән чыгару өчен, түбәндәгеләр буенча, Милекче белән килешү кирәк түгел:

а) Муниципаль учреждениеләр белән:

– муниципаль китапханәләр фондларын, югарыдагы ведомстволары җитәкчеләре белән килешү буенча исәптән чыгару;

– "матди активлары булмаган" статьялардан искәрмәләрсез хокуклары булган программа продуктларын;

– беренчел бәясе 40 000 сумнан артмаган төп чаралар объектлары (югарыдагы ведомстволары җитәкчеләре белән килешү буенча); муниципаль унитар предприятияне хосусыйлаштыру процессында булдырылган муниципаль унитар предприятияләр, муниципаль оешмалар, хуҗалык җәмгыятьләре балансында булган, әгәр дә бу фондлар (чыгымнар) күрсәтелгән җәмгыятьләрнең устав фондына кертелгән булмаса һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында (алга таба – Милекче) муниципаль милек булып тора, шулай ук түләүсез файдалану буенча бирелгән хокукы, ышанычлы идарә итү һәм башка хокуклары нигезендә исәптән чыгару тәртибен билгели

б) күчемсез милек объектларына карамаган муниципаль унитар предприятияләрнең һәм транспорт чаралары, мораль һәм физик яктан тузган очракта, аварияләрне, бәла-казалар һәм гадәттән тыш хәлләрне бетерүгә карата төп чараларны, әгәрдә болар, предприятияләрнең технологик циклын бозмаса яки региондагы

экологик хәлне начарайтмаса. Бу очракта муниципаль унитар предприятияләр, 2003 елның 13 октябрендә кабул ителгән 91н номерлы Россия Федерациясе финанс Министрлыгы боерыгы белән расланган бухгалтер хисабының төп чаралары методик күрсәтмәләре һәм 2001 елның 30 мартында кабул ителгән 26н номерлы Россия Федерациясе финанс Министрлыгы боерыгы белән расланган ПБУ 6\01 "Исәпкә алуны төп чаралары" бухгалтер хисабы Положениясе белән бәйле рәвештә ОС-4 номерлы форма буенча Милекчегә, бирелгән тәртиптә рәсмиләштерелгән актларын тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль милегендә булган төп фондларны һәм чыгымнар буенча тормышка ашырылмаган төзелеш объектларын исәптән чыгару, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе билгеләгән состав һәм аның тарафыннан расланган даими комиссия (алга таба Комиссия) катнашында үткәрелә.

5. Муниципаль унитар предприятияләр Милекчегә, күчемсез милек объектларына караган һәм транспорт чараларының төп чараларын исәптән чыгарганда түбәндәге документларны тәкъдим итә:

- милекне исәптән чыгаруга нигезләнгән хат;
- предприятие җитәкчесенең, төп фондларны исәптән чыгару өчен даими комиссия булдыру турындагы приказ копиясе;
- предприятие җитәкчесенең, төп чараларны (ОС-4 яки ОС-4а формасы) яки чыгымнар буенча тормышка ашырылмаган төзелеш объектларын исәптән чыгару буенча, шартлы елы 3 айдан да артмаган выбытия нәтиҗәсе актның икенче ягына язылырга тиеш, мөһер белән расланган акт:
- объектны караган Комиссия әгъзасе тарафыннан төзелгән акт:
- объект фотосы.

Күчемсез милек объектлары өчен өстәмә рәвештә тапшырыла:

- күчемсез милекнең техник паспорты (булганда);
- күчемсез милек урнашкан җир кишәрлегенә документлар.

6. Муниципаль учреждениеләр, мораль һәм физик яктан тузу буенча яраксызга чыккан, авариядән соңгы ликвидацияләр, бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләргә эләккән муниципаль милекләрне исәптән чыгарганда түбәндәге документларны тапшырырга:

а) күчемсез милек объектларын һәм транспорт чараларын исәптән чыгару өчен:

- милекне исәптән чыгаруга нигезләнгән хат;
- предприятие җитәкчесенең, төп фондларны исәптән чыгару өчен даими комиссия булдыру турындагы приказ копиясе;
- предприятие җитәкчесенең, төп чараларны (ОС-4 яки ОС-4а формасы) яки чыгымнар буенча тормышка ашырылмаган төзелеш объектларын исәптән чыгару буенча, шартлы елы 3 айдан да артмаган выбытия нәтиҗәсе актның икенче ягына язылырга тиеш, мөһер белән расланган акт;
- объектны караган Комиссия әгъзасы тарафыннан төзелгән акт:
- объект фотосы
- китерелгән зарар буенча җитәкче тарафыннан расланган акт.

Күчемсез милек өчен өстәмә рәвештә тапшырыла:

- күчемсез милекнең техник паспорты (булганда);
- күчемсез милек урнашкан җир кишәрлегенә документлар.

б) эшче машиналарны, компьютер техникасын һәм җайланмаларын исәптән чыгару өчен:

- милекне исәптән чыгаруга нигезләнгән хат;
- җитәкченең, төп фондларны исәптән чыгару өчен даими комиссия булдыру турындагы приказ копиясе;
- җитәкченең, төп чараларны (ОС-4 яки ОС-4а формасы) яки чыгымнар буенча тормышка ашырылмаган төзелеш объектларын исәптән чыгару буенча, шартлы елы 3 айдан да артмаган выбытия нәтиҗәсе актның икенче ягына язылырга тиеш, мөһер белән расланган акт;
- тиешле лицензиясе булган оешмадан техник экспертиза нәтиҗәсе;
- китерелгән зарар буенча җитәкче тарафыннан расланган акт.

Авариягә эләгеп яраксызга чыккан транспорт чараларын исәптән чыгаруга өстәмә документлар:

- юл хәләкәте турында акт;
- тикшерү органнары тарафыннан җинаять эшен кузгату яки туктату турында (булганда) карар;
- учреждения җитәкчесенең гаепле затларга карата чаралар күрүе турына хат;
- учреждениядән зыянны кайтару турында белешмә.

7. Хуҗалык җәмгыятләре мораль һәм физик яктан тузу буенча яраксызга чыккан, авариядән соңгы ликвидацияләр, бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләргә эләккән муниципаль милекләрне исәптән чыгарганда түбәндәге документларны тапшырырга:

- милекне исәптән чыгаруга нигезләнгән хат;
- хуҗалык җәмгыятләре җитәкчесенең, төп фондларны исәптән чыгару өчен даими комиссия булдыру турындагы приказ копиясе;
- хуҗалык җәмгыятләре җитәкчесенең, төп чараларны (ОС-4 яки ОС-4а формасы) яки чыгымнар буенча тормышка ашырылмаган төзелеш объектларын исәптән чыгару буенча, шартлы елы 3 айдан да артмаган выбытия нәтиҗәсе актның икенче ягына язылырга тиеш, мөһер белән расланган акт;
- объектны караган Комиссия әгъзасы тарафыннан төзелгән акт:
- объект фотосы
- китерелгән зарар буенча җитәкче тарафыннан расланган акт.

Авариягә эләгеп яраксызга чыккан транспорт чараларын исәптән чыгаруга өстәмә документлар:

- юл хәләкәте турында акт;
- тикшерү органнары тарафыннан җинаять эшен кузгату яки туктату турында (булганда) карар;
- хуҗалык җәмгыятләре җитәкчесенең гаепле затларга карата чаралар күрүе турына хат;
- хуҗалык җәмгыятләреннән зыянны кайтару турында белешмә.

Күчемсез милек өчен өстәмә рәвештә тапшырыла:

- күчемсез милекнең техник паспорты (булганда);
- күчемсез милек урнашкан җир кишәрлегенә документлар.

8. Әгәр, тәкъдим ителгән документлар нигезендә Положениянең 5-7 пунктларында санап кителгән, исәптән чыгаруны башкарып булмаган очракта,

Комиссия, өстәмә документлар бирүне (техник экспертиза, эксперт нәтиҗәсе) дәлилләү өчен запрос җибәрә.

9. Комиссия, бирелгән документлар нәтиҗәсендә, исәптән чыгарырга яки чыгармаска дигән карар нигезендә, муниципаль милекне исәптән чыгару мәсьәләсен карый һәм беркетмә төзи.
10. Муниципаль милекләрне исәптән чыгарудан баш тарту өчен түбәндәге очраклар булырга мөмкин:

- милекне исәптән чыгару нәтиҗәсендә технологик цикл бозылу;
- рөхсәт алу өчен бирелгән документлар дөрес рәсмиләштерелмәгән булса яки тәкъдим ителгән документларда аңлы рәвештә мәгълүматлар бозылган булса;
- муниципаль унитар предприятия милкенә арест яки аның исәп-хисап һәм башка счетларына арест булса;
- муниципаль унитар предприятия арбитраж суд карары белән банкротлыкка төшсә, шулай ук муниципаль унитар предприятияләр, муниципаль һәм дәүләт учреждениеләренең, вәкаләтле органнар тарафыннан бетерелүе турында карар булса;
- муниципаль милекләренең, хуҗалык алып бару  турында карар беркетелмәсә (оператив яки ышанычлы идарә, түләүсез файдалану);
- регионда экологик хәлнең бозылу куркынычы булса;
- Положениянең 5-7 пунктларында күрсәтелгәннәр буенча документлар пакеты тулы булмаса;
- гамәлдәге законнарда каралган башка очракларда;
- гамәлдәге законнарда каралган, исәптән чыгаруга куелган муниципаль милекләрне сату турындагы Хуҗасы кабул иткән карар булса.

11. Документлар, Милекчегә килеп ирешкәннән соң, 30 көн дәвамында каралырга тиеш. Комиссия беркетмәсе нигезендә, муниципаль милекләрне исәптән чыгару яки исәптән чыгаруны кире кагу буенча Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Карар чыгарыла.

Чыгарылган карар нигезендә, муниципаль унитар предприятия, муниципальных учреждениеләр һәм хуҗалык оешмалары җитәкчеләре:

- бухгалтерлык хисабында чагылдырылган, предриятия балансында булган муниципаль милекләрне исәптән чыгаруны гамәлгә ашыралар;
- Питрәч муниципаль районы муниципаль милеге Реестына, үзгәрешләр кертү өчен, вакытында тиешле документларны тәэмин итәләр;
- муниципаль милекләрене хуҗалык карамагына теркәү өчен (оператив яки ышанычлы идарә, түләүсез файдалану, аренда) буенча договорларга өстәмә килешү төзиләр;
- күчемсез милек объектынын җимерү буенча АҖ «Техник инвентаризация бюро сы» на белешмә (акт) бирәләр.

12. Төп фондларны һәм шулай ук  муниципаль унитар предприятияләр балансында торучы чыгымнар буенча тормышка ашырылмаган һәм (яисә) мөмкин булмаган төзелеш буенча  исәптән чыгарудан килгән зыян түбәндәгечә каплана:

- объектның баштагы бәясенең недоамортизированной өлеше финанс хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләренә карый;
- арту бәясе белән бәйле кыйммәтләү төп фондлар карый,

13. Муниципаль учреждения балансында булган төп фондларны исәптән чыгарудан килгән зыян, әлеге оешмалар сметасы хисабына ябылырга тиеш.
14. Исәпләгәндә килгән зыянны, төзелеш конструкцияләренең кире кайтарылган материаллар һ.б., бу материалларны сүтү, урнаштыру (слкадирование), саклау бәяләре каралырга тиеш.
15. Баланста хуҗалык җәмгыятләрендә һәм муниципаль милкендә булган, кире кайтарылган һәм утильләштерелгән төп фондларны керемгә кертүдән килгән табыш, билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы бюджетына күчерелә.
16. Милекне исәптән чыгарганда, Положенияне, башка норматив хокукый актларны бозу, гамәлдәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тарта.